| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 24 апрель г.Казань № 281

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының эш планы турында» 2020 ел, 28 декабрь, 1201 нче карары белән расланган 2021 елга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының эш планына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының эш планы турында» 2020 ел, 28 декабрь, 1201 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 26 февраль, 101 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының эш планына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

III «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын кабул итәргә кирәк булган мөһим мәсьәләләр» бүлегендә:

икенче һәм унөченче юлларда «Татарстан Республикасы Социаль-икътисадый мониторинг комитеты» сүзләрен төшереп калдырырга;

утыз беренче юлда «Татарстан Республикасы Социаль-икътисадый мониторинг комитеты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

ундүртенче һәм утыз бишенче юлларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

егерме икенче һәм егерме өченче юлларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «2021 елның II кварталы өчен тулаем Татарстан | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм | июль |

| | | |
|---|---|---|
| Республикасы буенча минималь куллану бюджетының кыйммәти күләмен раслау турында | социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсе | |
| 2022 елга Татарстан Республикасында халыкның җан башына һәм халыкның төп социаль-демографик төркемнәре буенча яшәү минимумы күләмен раслау турында | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы (килешү буенча), «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсе | сентябрь». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин